ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.08.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2114**

Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртү хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкаланы раслау турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртү хокукына ачык конкурста катнашучыларның заявкалары критерийларын бәяләү өчен шкаланы кушымтада каралганча расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С. Анисимовка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (төзелеш, инфраструктура, экология) йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

# Ташучылар заявкаларын бәяләү критерийлары

| № т/б | Критерияләр / параметрлар | Таләпләргә туры килә | Таләпләргә туры килми |
|---|---|---|---|
| 1. | Конкурс уздыру турында хәбәрдә бәян ителгән хәрәкәтчән составка карата таләпләргә туры килә торган кучмә состав булу һәм йөртүченең милек хокукында яисә башка законлы нигездәге конкурс документациясе булу; | | |
| 1.1. | Сыйдырышлыгы:<br><br>Утыру урыннары кимендә______ һәр берәмлек өчен исәп-хисаптан (конкурс документациясе нигезендә) | 1 | 0,5 |
| 1.2. | Транспорт чараларын һәр берәмлек өчен исәпләп ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы белән җиһазландыру | 1 | 0 |
| 2. | Пассажирлар йөртү буенча ташучының эш тәҗрибәсе (шул исәптән әлеге маршрутта); | Һәр эшләгән ел өчен 2 балл, әмма 10 баллдан артык түгел | 0 |
| 3. | Транспорт чараларын ташу өчен тәкъдим ителгән характеристикалар (елы, ягулык төре, экологик күрсәткече, техник структурасы, гражданнарның аерым категорияләре өчен куллану уңайлылыгы); | | |
| 3.1 | Хәрәкәт составы җитештерелгән ел:<br><br>- 80% хәрәкәт составы булу, 1 елдан да артык  җитештерелгән ел өчен;<br><br>- эшләү өчен 60% хәрәкәт составы булу,  1 елдан да артык җитештерелгән ел өчен;<br><br>- эшләү өчен 40 %ы хәрәкәт составы булу ,1 елдан да артык җитештерелгән ел өчен; | 15<br><br>10<br><br>5 | 0 |
| 3.2. | Кулланыла торган ягулык төре, һәр берәмлеккә исәпләгәндә:<br><br>газ-мотор ягулыгы<br><br>- дизель ягулыгы | 2 | 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 0,1 | |
| 3.3 | Экологик күрсәткечләр (һәр берәмлеккә исәпләгәндә):<br>-ЕВРО-5 двигателе ;<br>- ЕВРО-4 двигателе;<br>- ЕВРО-3 двигателе. | 1<br>0,2<br>0,1 | 0 |
| 3.4. | Техник структура:<br>Конкурс документациясендә күрсәтелгән классы, хәрәкәт составы булуы, һәр берәмлеккә исәпләгәндә | 0,2 | 0,1 |
| 3.5. | Гражданнарның аерым категорияләре өчен транспорттан файдалану уңайлыклары:<br>инвалид-коляскадагы  пассажирларны йөртү өчен җиһазландырылган бер берәмлек һәм аннан күбрәк хәрәкәт составы булу | 2 | 0 |
| 4. | Машина куеп тору, техник хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәт составын  ремонтлау  , машина йөртүчеләрне рейс алды, рейстан соң медицина тикшерүләре , транспорт чараларының, рейс алдыннан транспорт чараларының техник торышын контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә торган биналар һәм җиһазлар , диспетчерлык хезмәтләренең , юл хәрәкәте иминлеге кабинетлары булу | | |
| 4.1. | Хәрәкәт составы стоянкасы өчен мәйданчык (ачык яки ябык) булу | 10 | 0 |
| 4.2. | Хәрәкәт составына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау постлары булу | 10 | 0 |
| 4.3. | Машина йөртүчеләрне рейс алдыннан һәм рейстан соң тикшерүнең җиһазландырылган медицина кабинеты булуы<br>(раслый торган документлар кушымтасы белән) | 10 | 0 |
| 4.4. | Линиягә чыкканчы һәм линиядән кайткач хәрәкәт итүче составның махсус техник контроль пункты булу (техник контроль бүлеге)<br>(раслый торган документлар кушымтасы белән) | 10 | 0 |
| 4.5. | Хәрәкәт составын чыгаруның махсус диспетчерлык хезмәте булу (раслый торган документлар кушымтасы белән) | 10 | 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.6. | Юл хәрәкәте иминлеге кабинетлары булу | 10 | 0 |
| 5. | Автомобиль транспортында пассажирлар йөртү буенча хезмәт күрсәтүнең ярашканлык сертификаты булу | 10 | 0 |
| 6. | Транспорт чараларына, машиналарга, җайланмаларга техник хезмәт күрсәтүгә һәм ремонтлауга хезмәт күрсәтүләр сертификаты булу | 10 | 0 |
| 7. | Транспорт чаралары йөртүчеләре гаебе һәм конкурсларда катнашучыларның транспорт дисциплинасы буенча авариялелек торышы турындагы мәгълүматларны, шулай ук конкурста катнашучыларның Россия Федерациясе законнары таләпләрен, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актларны һәм техник нормаларны үтәмәүләре турындагы мәгълүматны анализлау.<br>*эш тәҗрибәсе булмаганда әлеге критерий исәпкә алынмый* | 5 | 0 |